ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

# КАРАР

«30» июнь 2021 ел Кече Шилнә авылы № 17

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 маендагы «Кече Шилнә авыл җирлеге хакимияте каршында балигъ булмаганнар эше буенча иҗтимагый комиссия төзү турында» 14 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында

«Балигъ булмаганнарның күзәтүсезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» 1999 елның 24 июнендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2021 елның 26 маендагы «Кече Шилнә авыл җирлеге хакимияте каршында балигъ булмаганнар эше буенча иҗтимагый комиссия төзү турында» 14 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http//pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Кече Шилнә
авыл җирлеге Башлыгы А.Г. Даутов